Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Югары Чура авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

**«2» июль 2020 ел** **№13**

Җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 нче пункты нигезендә, җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле салымнар буенча недоимканы һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны (алга таба – бурыч) түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- 3 елдан артык бурыч барлыкка килү датасына вафат булган яисә Россия Федерациясе Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм милкенә салым буенча;

- мирас хокукыннан варислар баш тарткан очракта, варислар булмаган яки мирас ачылган көннән бер ел эчендә мирас алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм милкенә салым буенча.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев